**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ СТАРОКАШИРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**ул. Комсомола, дом 4а. с. Старый Кашир,**
**423357 телефон (85559) 4-86-36**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ КӘШЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
**Иске Кәшеравылы, Комсомол урамы,**
**4а йорты, 423357, телефон (85559) 4-86-36**

ОКПО 93068309 ОГРН 1021601312215 ИНН/КПП 1636001259/163601001

Решение Карар

Иске Кәшер авылы № 26 «22»ноябрь 2018г.

Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге Советынын 2014 елның 18 ноябрендәге 14 санлы «Физик затлар милкенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлеше 2 пункты, «Россия Федерациясе Салым кодексының 52 статьясына беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 августындагы 334 - ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Салым кодексының 56, 399 статьяләренә нигезләнеп, Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге Советының 18.11.2014 ел, 14 санлы «Физик затлар милкенә салым турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.2.1. подпунктына «фатирлар» сүзеннән соң «фатир өлешләре» сүзләрен өстәргә.

2) 2.3.1. подпунктына «торак йортлар» сүзләреннән соң «торак йортларның өлешләре» сүзләрен өстәргә.

3) 3нче пунктка түбәндәге эчтәлектәге 3.1нче подпункт өстәргә:

«3.1. Ел башына унсигез яше тулмаган өч һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләнең, шул исәптән үги балалары, опека һәм попечительлеккә алынган балалары булган күп балалы гаиләнең, ата-ананың икесенең берсенә салым салынучы бер объектына (сайлап алып) физик затлар милкенә салымның түбәнәйтелгән ставкасы рәвешендә салым ташламасын билгеләргә:

| Объект төре | Гамәлдәге ставка | Ташламалы ставка |
|---|---|---|
| Шәхси торак йорт яки торак йортның бер өлеше | 0,3 | 0,15 |
| Күпфатирлы йортта торак бина (фатир, фатирның бер өлеше, бүлмә) | 0,2 | 0,1 |

Салым ташламасына хокукны раслаучы документлар салым түләүчеләр - физик затлар тарафыннан салым салу объекты булган мөлкәт урнашкан урындагы салым органнарына, үткән салым чорыннан соң килүче елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, тапшырыла.».

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә, шулай ук мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3.Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин халыкка игълан ителгән көннән соң бер айдан да иртәрәк түгел.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Кәшер авыл җирлеге Советы рәисе Р.Н.Давлетзянов